| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14 март 2014 ел № 10-7/кс

**Казан шәһәре**

***ҖЧҖ «Торак хуҗалыгы һәм төзекләндерү күптармаклы җитештерү берләшмәсе» тарафыннан каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү хезмәте күрсәтүгә тарифны билгеләү***

“Коммуналь комплекс оешмалары тарифларын җайга салу нигезләре турында” 30 декабрь, 2004 ел, № 210-ФЗ Федераль законга, “Коммуналь комплекс оешмалары эшчәнлеге өлкәсендә бәя кую нигезләре һәм тарифларны, өстәмәләрне һәм чик индексларны җайга салу тәртибе турында” 14 июль, 2008 ел, № 520 Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15 июнь, 2010 ел, № 468 карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга № 1 кушымта нигезендә, ҖЧҖ «Торак хуҗалыгы һәм төзекләндерү күптармаклы җитештерү берләшмәсе» тарафыннан күрсәтелә торган каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү хезмәте күрсәтүгә тарифны календарь бүленеш нигезендә билгеләргә.

2. Бу карарның 1 пунктында билгеләнгән тариф 2014 елның 1 маеннан 2017 елның 30 апреленә кадәр үз көчендә була.

3. Бу карарның 2 пунктында күрсәтелгән тарифның гамәлдә булу чорына, № 2 кушымта нигезендә, каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү өлкәсендә ҖЧҖ «Торак хуҗалыгы һәм төзекләндерү күптармаклы җитештерү берләшмәсе» производство программасының төп күрсәткечләрен килештерергә.

4. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 30 декабрь, 2009 ел, № 1140 карары белән расланган мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифны билгеләү турында карар кабул ителгәннән, соң 30 көннән дә соңга калмыйча ҖЧҖ «Торак хуҗалыгы һәм төзекләндерү күптармаклы җитештерү берләшмәсе» халыкка җиткерелергә тиешле мәгълүматны ачарга тиеш.

5. Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү хезмәте күрсәтүгә бу карарда билгеләнгән тариф “Коммуналь комплекс оешмалары товарларының

һәм хезмәтләр күрсәтүләренең кулланучылар өчен куллану мөмкинлеге критерийлары системасын билгеләү турында” 27 февраль, 2012 ел, № 45 Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты боерыгы белән расланган коммуналь комплекс оешмалары товарларының һәм хезмәтләр күрсәтүләренең кулланучылар өчен куллану мөмкинлеге критерийларына туры килә.

6. Түбәндәге карар рәсми нәшер ителгәннән соң ун көн узгач тулы көченә ия була.

Татарстан Республикасы
тарифлар буенча
дәүләт комитеты Рәисе М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча дәүләт комитетының
14 март 2014 ел № 10-7/кс
карарына 1нче кушымта

ЖЧЖ «Торак хуҗалыгы һәм төзекләндерү күптармаклы җитештерү берләшмәсе» тарафыннан каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү хезмәте күрсәтүгә тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлек, коммуналь комплексы оешма исеме | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү хезмәте күрсәтүгә тарифлар, сум./куб.м | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2014 01 маеннан алып 2014 елның 30 июненә хәтле | 2014 елның 01 июленнән алып 2015 елның 30 апреленә хәтле | 2015 елның 01 маеннан алып 2015 елның 30 июненә хәтле | 2015 елның 01 июленнән алып 2016 елның 30 апреленә хәтле | 2016 елның 01 маеннан алып 2016 елның 30 июненә хәтле | 2016 елның 01 июленнән 2017 елның 30 апреленә хәтле |
| | Алабуга муниципаль районы | | | | | | |
| 1 | ЖЧЖ «Торак хуҗалыгы һәм төзекләндерү күптармаклы җитештерү берләшмәсе» (ӨБС исәпкә алынмаган) | 75,60 | 79,29 | 79,29 | 82,54 | 82,54 | 85,86 |

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча дәүләт комитетының
14 март 2014 ел № 10-7/кс
карарына 2нче кушымта

## Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү хезмәте күрсәтү өлкәсендә ЖЧЖ «Торак хуҗалыгы һәм төзекләндерү куптармаклы җитештерү берләшмәсе» җитештерү программасының төп күрсәткечләре

| № п/п | Коммуналь комплексы оешмасының исеме | 01 май 2014 - 30 апрель 2015 ел | | | | | 01 май 2015 ел - 30 апрель 2016 ел | | | | | 01 май 2016 ел - 30 апрель 2017 ел | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Коммуналь комплексы оешмасының җитештерү программасы күрсәткечләре, мең.куб.м | | | | Кирәкле тулай керем, мең сум. (ӨБС керми) | Коммуналь комплексы оешмасының җитештерү программасы күрсәткечләре, мең.куб.м | | | | Кирәкле тулай керем, мең сум. (ӨБС керми) | Коммуналь комплексы оешмасының җитештерү программасы күрсәткечләре, мең.куб.м | | | | Кирәкле тулай керем, мең сум. (ӨБС керми) |
| | | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү күләме, шул исәптән: | | | | | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү күләме, шул исәптән | | | | | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү күләме, шул исәптән | | | | |
| | | Барлыгы | Кулланучылар | Бюджет тагы куллану чылар | Башка кулланучылар | | Барлыгы | Кулланучылар | Бюджет тагы куллану чылар | Башка кулланучылар | | Барлыгы | Кулланучылар | Бюджет тагы куллану чылар | Башка кулланучылар | |
| 1 | ЖЧЖ «Торак хуҗалыгы һәм төзекләндерү куптармаклы җитештерү берләшмәсе» | 53,98 | 0,0 | 0,0 | 53,98 | 4180,40 | 53,98 | 0,0 | 0,0 | 53,98 | 4367,74 | 53,98 | 0,0 | 0,0 | 53,98 | 4545,02 |